**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10 август, 2022 ел** **№ 185**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеклегенең генераль планын әзерләү зарурлыгы булмау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеклегенең территориясендә җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавына бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасын һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районын территориаль планлаштыру схемалары тарафыннан федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмаганга, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеклегенең Генераль планын әзерләү зарурлыгы булмавын танырга.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль район Советының 31 март 2022 елның 159нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман, Мүлмә, Усад авыл җирлекләре генераль планнарын әзерләү зарурлыгы булмау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров